**СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БОЛГАР»**
**СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# КАРАР

№ 46-1 « 07 » октябрь 2019 ел

**«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге**
**территориясендә үзара салым кертү**
**мәсьәләсе буенча һәм гражданнарның**
**үзара салым акчаларын куллану турында**
**җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Болгар шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 1 октябрендәге 35 номерлы «Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында» карары нигезендә, ТР Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елның 1 декабренә ТР Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муницпаль берәмлеге территориясендә 2020 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?

**Җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:**

- Некрасов ур., Дзержинский ур., Октябрь ур., Нариманов ур., Пушкин ур., Солнечная ур., Матросов ур., З.Космодемьянская ур, Ленин ур, Нагаев ур. суүткәргеч челтәрен реконструкцияләү, задвижкалар урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге торак пунктлары территориясендә 2019 елның 8 октябреннән алып мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://spasskiy.tatarstan.ru/ 2019 елның 8 октябереннән урнаштырырга.
5. Әлеге карарны «Новая жизнь»- «Яңа Тормыш» район газетасында бастырырга» 09.10.2019 ел.
6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**“Болгар шәһәре” муниципаль берәмлек**
**Башлыгы урынбасары** **С.И.Тюнев**

СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БОЛГАР»